КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 16 гыйнвар г.Казань № 19

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан Экспо» конгресс-күргәзмә, мәдәни, тамаша-күңел ачу, спорт-массакүләм һәм социаль юнәлешле чараларны үстерү һәм аларга ярдәм итү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешманың күзәтү советына Татарстан Республикасы вәкилләрен билгеләү турында» 2019 ел, 25 октябрь, 958 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан Экспо» конгресс-күргәзмә, мәдәни, тамаша-күңел ачу, спорт-массакүләм һәм социаль юнәлешле чараларны үстерү һәм аларга ярдәм итү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешманың күзәтү советына Татарстан Республикасы вәкилләрен билгеләү турында» 2019 ел, 25 октябрь, 958 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 3 октябрь, 1066 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Казан Экспо» конгресс-күргәзмә, мәдәни, тамаша-күңел ачу, спорт-массакүләм һәм социаль юнәлешле чараларны үстерү һәм аларга ярдәм итү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешманың күзәтү советыннан Ф.Ә.Әһлиуллинны чыгарырга;

«Казан Экспо» конгресс-күргәзмә, мәдәни, тамаша-күңел ачу, спорт-массакүләм һәм социаль юнәлешле чараларны үстерү һәм аларга ярдәм итү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешманың күзәтү советына Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры Азат Рифгать улы Кадыйровны билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин